*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

# ТЫЛСЫМ+

Өченче сан

Ноябрь, 2014 нче ел

**Бу санда:**

*Синә әйтер сүзем бар, әнием* 2

*Мөслим районы авыллары тарихы: үткәне, бүгенгесе, киләчәге* 3

*Мәдәният елына багышланган концерт-тамашадан фоторепортаж* 4

**Аналар турында татар халык мәкальләре**

*Ана – шәфкать диңгезе.*


*Ана яхшылыгын авырсаң белерсен.*

*Анаңдай ана булмас.*

*Анасыз корт бал җыймас, бал җыйса да мул җыймас.*

*Тән биргән дә - ана, сөт биргән дә - ана, тел биргән дә - ана, көй биргән дә - ана.*

## 30 НЧЫ НОЯБРЬ—ХАЛЫКАРА АНАЛАР КӨНЕ



Кадерле әниләребез! Ноябрьнең соңгы якшәмбесендә без Әниләр көнен зурлап билгеләп үтәбез, җир йөзендәге иң бөек затларга ихлас рәхмәтебезне белдерәбез.

Һәрберебезнең тормышы сезнең ярдәмнән һәм наздан, сезнең бишек җырыннан һәм кайгыртудан башлана. Һәркем гомере буе әнисенең якты хатирәсе белән яши, аның куллары һәм йөрәге җылысын тоя, сөйкемле елмаюын хәтерендә саклый.

Ана булу – гаять олы, мактаулы һәм җаваплы бурыч. Шуңа да аналарны һәм балаларны яклауга, аларның тормышкөнкүреше белән бәйле социаль мәсьәләләрне хәл итүгә зур игътибар бирелә. Гимназиябездә дә әлеге юнәлештә күптөрле программалар, чаралар күрелә, максатчан гамәлгә ашырыла.

Укыту-тәрбия - бердәм процесс. Без этиләрнең һәм әниләрнең ролен, ярдәмен тоябыз. Безне уртак максатлар берләштерә. Бер-беребезне аңлап, киңәшләшеп эшләргә омтылабыз. Әниләрнең шәхси үрнәге дә, чын йөрәктән чыккан акыллы киңәшләре дә, кирәк вакытта таләпчән булулары да әһәмиятле. Барлык әниләргә, әбиләребезгә, апа-сеңелләргә ныклы сәламәтлек, озын гомер, бәхет телибез. Гаилә учагыгыз сүрелмәсен, балаларыгызның бәхетен, игелеген күреп, сәламәт булып, тыныч, имин тормышта яшәргә язсын.

Гимназия коллективының зур күпчелеге - хатын-кызлар - күбесе үзләре дә әниләр. Форсаттан файдаланып, гимназиядә хезмәт куючы барлык укытучыларны, сәламәтлек, чисталык һәм тәртип сагында торучыларны, тәмле ризыклар белән сөендерүче хезмәткәрләребезне Әниләр көне белән тәбрик итәм. Укыту-тәрбия процессына Сезнең һәрберегезнең чиксез зур өлеше керә. Изге бәйрәм уңаеннан иң җылы һәм ихлас котлауларымны кабул итегез.

***Гимназия директоры***
***А.Ф. Мирзаянов***

### Хөрмәтле әниләр!

Әйтәсебез килә бүген
Кадерле әниләргә -
Бу бәйрәм дөньяга килгән
Кояш нуры сибәргә!

Бу бәйрәмдәге җылылык
Гасырларга җитәрлек.
Сезнең назлы кулларыгыз
Әкиятне чын итәрлек.

Наз гөлләре үсеп чыга
Сез үткән буш җирләрдән.
Кабул итегез котлаулар
Безнең кебек балалардан!

***Укучылар үзидарәсе***



# СИҢА ӘЙТЕР СҮЗЕМ БАР, ӘНИЕМ



## Ана дигән хәзинә

Әнкәй йорты – алтын бишек. Өйнең яме ана белән. Мәктәптән йөгерә-йөгерә өйгә кайтабыз, чөнки өйдә әни көтә. Эштән арып кайтса да, ул кояш кебек балкып тора. Бөтен серләребезне, кайгы-шатлыкларыбызны, әлбәттә, иң беренче чиратта, әниләребезгә сөйлибез.

Минем әнием – Ильмира, химия, биология фәннәрен укыта. Куллары алтын аның. Пешергән ризыклары – телеңне йотарлык. Әтиебез Радик белән безгә, абыем белән икебезгә, матур тәрбия бирергә тырышалар.

Тән биргән дә - ана, сөт биргән дә - ана, тел биргән дә - ана, көй биргән дә - ана. Әниләр алдында бурычыбызны беркайчан да түләп бетерә алмабыз. “Бер әнкәне мең нәнкә дә алыштыра алмас” дигән халык әйтеме минем йөрәгемә кереп калды. Аналарны кадерләп, яратып, йөзләренә кызыллык китермичә яшәргә тырышырга кирәк. Ана ул – хәзинә. Хәзинәне кадерләп сакларга кирәк.

***Инзилә Сәфәргалина,***
***8 нче а сыйныфы укучысы***

## Әни йөрәге – иң сизгер йөрәк

Әни күзләре мәңге сүнмәс бәхет, шатлык уты белән яна. Әни йөрәге сизгер йөрәк булып кала. Әнинең мәрхәмәтле елмаюы гына ни тора!

Һәр кеше әнисен бик ярата. Ә минем өчен ул җир йөзендә иң якын, иң кадерле кеше. Ул безгә тормыш биргән, кадерләп, тәрбияләп үстергән.

Минем әнием вакытында назлый да, кирәгендә ачулана да белә. Аның биргән киңәшләрен мин һәрвакыт файдаланам. Әниемне мин бик яратам.

Әниләргә карата безнең мәхәббәтебез никадәр зур булса, тормышыбыз шулкадәр шатлыклы һәм якты булачак.

***Алсу Муллагалиева,***
***8 нче а сыйныфы укучысы***

## Әнием – ышанычлы терәгем

Миңа бу дөньяда иң кадерле кеше ул - әни. Әниемнең канаты астында үземне бәләкәй сары чебеш кенә итеп хис итәм. Миңа анда җылы, якты, йомшак, күңелемә тыныч, шуңа күрә үземдә ышаныч тоям.

Әнием минем ягымлы, сөйкемле, кешелекле, акыллы, эшчән. Ул - зур йөрәкле кеше. Аның күңел җылысы гаиләдәге өч балага да, әтиемә дә, әбиемә дә җитә.

Минем әнием фантазиягә бай. Ул үзе төрле рецептлар уйлап табарга, бөтенебезне шаккаттырырга ярата. Без беләбез: һәрвакыт безнең өстәлебез кайнар ризык, чәй тәмнәре белән тулы булачак. Мин әниемне бик тә нык яратам, һәм аңа озын гомер, сәламәтлек, хатын-кыз бәхете телим.

***Эльвина Солтанова,***
***8 нче а сыйныфы укучысы***

## Балалык рәхмәтем

Әнием! Минем иң кадерле кешем! Мине яратучы да, мине аңлаучы да, кирәк чакларда ярдәм итүче дә син бит бу дөньяда! Синнән башка тормышымны мин күз алдыма да китерә алмыйм. Миңа, апаема, абыема син зур терәк, таяныч. Безгә тәмле ризыклар пешерүче дә, матур-матур киемнәр алучы да, изге теләкләр теләп мәктәпкә озатучы да, әни, әти, сез бит! Аллага шөкер, гаилә җылысын тоеп, үз өебездә, үз гаиләбез белән яшибез.

Саклап торсын, яклап торсын
Әнием, теләкләрең.
Гомерләреңә җитәрлек,
Балалык рәхмәтләрем.

***Язилә Исмәгыйлова,***
***8 нче а сыйныфы укучысы***

## Әниләр була төрле

Әниләр була төрле
Милләте, теле, дине.
Һәр балага иң якыны -
Үзен үстергән әнисе .
Әни, аңлыйм, эшең авыр,
Бик арыйсыңдыр инде.
Атна саен көтеп алам
Өйгә кайтуларыңны.
Рәхмәтлемен сиңа, әни,
Тапкан-үстергән өчен,
Рәхмәтлемен сиңа, әни,
Бу дөньяда булганың өчен!

***Илнур Нуриев,***
***7 нче б сыйныфы укучысы***

## Котлау

Әни - ул дөньяда иң бөек кеше. Алар безне тугыз ай буе йөрәк түрләрендә йөртеп, безнең белән сөйләшеп, дөньяга китергәннәр, “бәбкәм” дип иркәләп кулларында назлаганнар, төн йокыларын йокламыйча, ару-талуларына карамыйча, безне бишектә тирбәтеп йоклатканнар, тәрбияләп үстергәннәр. Без аларга рәхмәтлебез, аларга беркайчан да кайгы, сагыш күрсәтергә тиеш түгел. Утызынчы ноябрь - әниләр көне. Без, унберенче сыйныф укучылары, чын күңелдән аларны бу шатлыклы бәйрәм белән котлыйбыз! Сезгә озын гомер, ныклы сәламәтлек, гаилә бәхете, эшегездә зур уңышларга ирешүегезне телибез. Балаларыгызның куанычын күреп яшәгез! Тормышыгызда барлык теләкләрегез чынга ашсын! Үз чиратыбызда, без дә сезнең өметышанычларыгызны акларга тырышырбыз. Безнең өчен сезгә кызарырга туры килмәс. Без - сезнең горурлыгыз булырбыз!

***Иң изге теләкләре белән***
***11 нче сыйныф укучылары***

## МӨСЛИМ РАЙОНЫ АВЫЛЛАРЫ ТАРИХЫ: ҮТКӘНЕ, БҮГЕНГЕСЕ, КИЛӘЧӘГЕ

### Сандугач оям минем

Минем бабам Әхмәтҗанов Мөҗәһит Заһит улының туган авылы Түрешкә багышланган “Сандугач оям минем” исемле китабы турында язасым килә. Бу китап авылга 90 яшь тулу уңаеннан язылган.

Әлеге җыентыкта Мөслим районы Түреш авылының күренекле шәхесләренә багышланган шигырьләр, багышлаулар, эпиграммалар, Бөек Ватан сугышына киткән һәм сугыш кырында ятып калган авылдашларның исемлеге тупланган.

Чыннан да, Түреш авылы табигатьнең иң матур почмагына урнашкан. Ул куе урманнарга, киң болыннарга, челтерәп аккан саф чишмәләргә бик бай.

Шигъри табигате, белемгә, мәдәнияткә омтылганлыгы, сабыр холыклы, итагатьлелеге белән Түреш авылы халкы аерылып тора. Шуңа күрә бу авылдан бик күп күренекле кешеләр: шагыйрьләр, язучылар, артистлар, эшмәкәрләр, танылган укытучылар чыккан.

Атаклы кешеләре белән тирә якка даны таралган. Авылга багышлап күп җырлар һәм шигырьләр язылган. Аларның кайберләре бу китапка да кертелгән.

Бабам Түреш авылындагы һәрбер йортны фотога төшереп, кайчан төзелгән, кемнәр яшәгән, бүгенге көндә хәле ничек - барысын да җыеп, китап язган.

2013 нче ел “Тарихи-мәдәни мирас елы” дип игълан ителгән иде. Менә шуңа күрә авылның һәр йорты, агачы, тау астында челтерәп аккан саф сулы чишмәсе - берсе дә юкка чыгарга тиеш түгел. Түреш чишмәсе Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Харрас Әюповның исемен йөрткәнгә күрә, аңа булган игътибар да көчәйде.

Түреш авылы чишмәләргә бик бай. Ерак та түгел, тау астындагы әрәмәлек эчендәге Куш Чишмәдән авыл халкы су алмаса да, без гаиләбез белән һәр яз кайтып, аны чистартып киләбез.

Ә быел килүебезгә, чишмәбез өстенә балчыклар ишелгән, юкка чыга язган. 9 нчы май көнне парадтан соң кайтып, чишмәбезнең юлын ачтык, ике улак куеп, тирәсен чистарттык. Бу эшне бетерүгә, кояш байый башлаган иде. Эшебезне күреп, бабам безгә багышлап шигырь дә язды. Ә үзем эшләребезне фотога, видеога төшереп, 



музыкалар белән презентация ясадым.

Шул көннән соң чишмәгә юл төште. Авылыбызга кайткан һәрбер кунак, шунда барып кайта, суын авыз итеп, үзенә көч-куәт ала.

Миндә дә зур горурлык хисе уятты Куш Чишмә. Чөнки минем ерак әби-бабаларым шушы чишмә 



суын эчеп, аны карап торганнар.

Мин аларның эшләрен дәвам итәргә бурычлы!!!

Язмамны бабамның шигыре белән тәмамлыйсым килә:

### *Куш Чишмә дә куанды*

Җиңү көнне, бәйрәмнән соң,
Карамыйча бер эшкә,
Утырдылар машинага,
Юнәлделәр Түрешкә.

Лилия, Алмаз, Булаттан
Зөлфәте дә калмады.
Куш Чишмәгә барачакны
Әллә каян аңлады.

Ә Куш Чишмә, мескенкәем,
Аларны күптән көткән.
Чөнки юлы томаланган-
Балчык ишелеп төшкән.

Көрәк белән юл ярдылар,
Тимер улак куйдылар.
Тырма тотып кулларына,
Чүп – чарларны җыйдылар.

Чыбык – чабыкларны кырып,
Хәтта сукмак салдылар.
Үзләренең эшләреннән
Бик канәгать калдылар.

***Булат Әхмәтҗәнов,***
***7 нче б сыйныфы укучысы***

### Туган авылым

Иске Вәрәш булса да,
Иске түгел – яна ул.
Үзе бик зур булмаса да,
Кешеләре күп аның.

Каз-үрдәкләр йөзәләр
Кечкенә инешендә.
Кызарып җиләкләр пешә
Яшел тау итәгендә.

Урманга да бик бай ул
Чишмәләргә-күлләргә.
Шомырт, баланнар үсә
Әрәмә эчләрендә.

“Дуслык” чишмәсе тавыннан
Күренә Ык буйлары.
Төшеп суларын эчсәң,
Басыла сусауларың.

***Алия Зарипова,***
***7 нче б сыйныфы укучысы***

### Туган авылыма

*(Әзрәк кенә Тукайчарак)*

Әби-бабай авыл өчен
Бик шәп урын сайлаган:
Уңда – урман, сулда – таулар,
Чишмәсе, инеше бар.

Туган авылым – Метрәй минем,
Чуерташлы су буе.
Йөрәкле Тау, Чишмә Башы,
Солтанай-каран, Нади Кулы...

Мәтрүшкәле аланнарның
Мең чиргә дәвасы бар.
Тау бөтнеге, гөлбадранның
Һәркемгә шифасы бар.

Тукай язганнан ким түгел
Бездә дә чыршы-нарат.
“Төпләрендә ятканым бар
Хәл җыеп күккә карап”.

Җәй көннәре җыя халык
“Кура җиләк тә җир җиләк”.
Кил әйдә, җыярсын син дә
“Күз ачып йомганчы бер чиләк”.

Сандугачлы болыннарда
Күбәләкләр уйныйлар.
Туган якның гүзәллеген
Көйгә салып җырлыйлар.

Метрәемнең халкы данлы,
Тырыш, уңган, мактаулы.
Булсам иде туган якның
Мин дә бер сандугачы.

***Әһлиуллина Язилә,***
***9 нчы б сыйныфы укучысы***

# ГИМНАЗИЯ КОЛЛЕКТИВЫ КОНЦЕРТЫННАН ФОТОРЕПОРТАЖ

Мәдәният елы кысаларында 17 ноябрь көнне Зифа Басыйрова исемендәге мәдәният сараенда гимназия коллективы көче белән әзерләнгән концерт-тамаша узды. Концертны Чулпан Хәйруллина һәм Илназ Башаров алып бардылар, сәнгать җитәкчесе – Гөлнур Фәхертдинова, сценарий авторы – Эльмира Тимергалиева.




Коллективның йөзек кашы - хор


Бию коллективы





"Серле йөрәк" кызлар вокаль ансамбле

## Укытучыларыбыз - сәхнә йолдызлары



Г.Ш. Мирзасалихова



*Илдар Юлдашев фотолары*



Л.Н. Арсланова



Әлмәндәр - А.Ф. Мирзаянов




Р.Р. Хантимеров, Р.М. Марданшина







Искәндәр - Р.Р. Хантимеров, Өммия - Р.М. Марданшина, Хәмдебану - Л.З. Шабаева, Әҗәл - Р.Г. Ахунов

ТЫЛСЫМ+

Ноябрь, 2014 нче ел

*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Исмәгыйлева Язилә
**Корректорлар:** Муллагалиева Алсу, Солтанова Эльвина
**Корреспондентлар:** Сәфәргалина Инзилә, Кашапова Илүзә
**Дизайнер:** Галиев Илназ

**Компьютерда җыючылар:** Гилемов Азат, Маннанов Илдар
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym